
## Хәбәрләр

### Лаеклы бүләк

**Озак еллар район башлыгы урынбасары булып эшләп, лаеклы ялга киткән Рәмис Хәялиев "Фидакарь хезмәт өчен" медале белән бүләкләнде.**

"Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Советы" Ассоциациясенең XX съезды кысаларында дәүләт бүләкләрен тапшыру тантанасы узды. Республика Рәисе Рөстәм Миңнеханов җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлары өчен муниципаль хакимият вәкилләрен бүләкләде. Бүләкләнүчеләр арасында район башлыгының элеккеге урынбасары, озак еллар буена җирле үзидарә системасында эшләгән Рәмис Хәялиев та бар. Аңа Татарстан Республикасының дәүләт бүләге – "Фидакарь хезмәт өчен" медале тапшырылды.



### Редакциягә яңа эш автомобиле кайтты

**Кайбыч районы журналистлары өчен куанычлы вакыйга булды – редакциягә яңа Лада Веста автомобиле кайтты.**

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов "Татмедиа" акционерлык җәмгыяте карамагындагы республика матбугат редакцияләренә барлыгы 48 Лада Веста һәм бер Лада Аура автомобиле алу өчен сертификатлар тапшырды.

– Бу машиналар редакцияләргә оператив бурычларны хәл итәргә ярдәм итәчәк. Сез туплаган һәм тараткан мәгълүмат халык өчен зур әһәмияткә ия, – диде Рөстәм Миңнеханов, редакторларга мөрәҗәгать итеп.

"Татмедиа" агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев бүгенге тизлек заманында вакыйгаларны тулы күләмдә яктырту өчен мобильлекнең иң мөһим шарт булып торуын билгеләп үтте.

Баш редактор Луиза Сөнгатуллина әйтеп узганча, яңа автомобиль журналистларга иң ерак авылларга да барып җитәргә, халыкны кызыксындырган яңалыкларны вакытында яктыртырга этәргеч булачак. "ТАТМЕДИА" логотибы төшерелгән яңа машина бирелү – редакциянең матди-техник базасын ныгыту гына түгел, ә район матбугатының статусын күтәрүче мөһим адым да.




## Геройларның даны мәңгелек

# Кайбычның билгесез Геройлары

## Югары исемгә лаек булып та, аны ала алмаган якташлар



Борындык авылында батыр авылдашлары Әбрар Җәләлиевнең җәсәден, 79 елдан соң туган ягына алып кайтып, җир куенына иңдерделәр. Фото редакция архивыннан алынды. /МИНГАЗИЗ СӨНГАТУЛЛИН ФОТОСЫ, «КАЙБЫЧ ТАҢНАРЫ».

### Мәңгелек хәтер

**Борындык авылында М.Рамил урамы бар. Бу – Әфганстан җирендә һәлак булган Рамил Мөхәммәтҗановның авылча якын итеп кыскартылган исеме. Бактың исә, алданрак Борындыкта андый кыскартылган урам исеме булган. Герой Әбрар урамы. Ник алай аталган соң, герой атамасы кайдан килгән? Чын дөресе, бу сорауга ачык итеп аңлатып бирүче юк иде.**

Калуга җирендә якташыбыз Әбрар Җәләлиевнең җәсәде табылып, туган җиргә алып кайтып җирләгәч, күп нәрсә ачыкланды. Пулеметчы Әбрар каты сугышларда соңгы тамчы каны тамганчы сугыша. Аның батырлыгы турындагы хәбәрләр бөтен Татарстанга тарала. ТАССРның зур төркем җәмәгатьчелеге илнең төп газетасы “Правда” аша татар сугышчыларына мөрәҗәгать бастыра. Үрнәк итеп иң билгеле геройлар арасында пулеметчы Әбрар Җәләлиев та күрсәтелә. Әмма, исеме бөтен илгә билгеле булса да, якташыбызга рәсми рәвештә Герой исеме бирелми кала. Борындыклылар исә үз героен онытмый.

Бу тарихка охшаш хәл Олы Урсак авылында да була. Танкист Рәхимулла Җиһаншин Бөек Ватан сугышының башыннан ахырынача яу кырында була. Соңгы тиңдәшсез батырлыгы 1945 елның 18 гыйнварында Польша җирендә була. Үзенең Т-34 танкы белән елга аша күпер һәм плацдармны яулап ала. Озак кына көрәшкәч, танк яна, экипаж һәлак була. Рәхимулла Җиһаншин бер ай эчендә Советлар Союзы Герое исеменә лаек дип күрсәтелә. Ләкин шушы иң югары исем урынына чираттагы орден бирергә карар кылына. Урсаклылар, батыр якташларының исемен мәңгеләштереп, авылның иң матур урамнарының берсенә Җиһаншин исемен кушалар. Халык телендә ул, бераз русчалаштырылып, Зиганшин урамы дип йөртелә.

Урсаклылар тагын бер якташ герой белән горурлана ала. Ул – Абрам Семенович Бикаев. Илебезнең төрле шәһәрләрендә укый, эшли. Офицер була. Мулла кушкан исемен әле табасы бар, чөнки бу исемнәр соңрак кушылган икәнлеге күренә. Абрам Бикаев сугышны, укчы батальон командиры булып, Германиянең үзәгендә тәмамлый. Шунда ук чираттагы зур батырлыклар күрсәтә. Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителсә дә А.Невский ордены белән генә бүләкләнә. Гомумән, мондый якташлар белән горурланырга да, исемен мәңгеләштергә дә кирәктер.

Чираттагы Герой – Турминский авылыннан Николай Корнилов. Кирәк бит! Бер үк авыллардан ничә герой күренә. Сержант, амфибия машиналар отделениесе командиры. 1942 елдан алып, сугыш ахырына кадәр, бик күп батырлыклар эшли. Соңгысы 1945 елның 25 апрелендә Кенигсберг шәһәрендә башкарыла. Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә. Инде сугыш беткәч, орден белән бүләкләнә.

Чираттагы ике герой кайбер чыганакларда икесе дә бер авылдан – Олы Колаңгыдан дип күрсәтелә. Кайберләрендә Александр Малов Федоровское авылыннан диелә. Туган ягында ачыклап бетерерләр. Шулай ук офицер, өлкән лейтенант, укчы рота командиры. Чираттагы батырлыгын 1944 елның августында эшли. Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә. Октябрь аенда орден белән бүләкләнә. Азрак билгеле булганча, сугыштан туган ягына кайтып, "Сельхозтехника"да эшли. Бу һәм башка геройларны авылдашлары тирәнрәк өйрәнсен иде.

Сергей Чумаков – Олы Колаңгыдан. Гвардия өлкән лейтенанты. Пулемет ротасы командиры. 1944 елның июнь аенда, Белоруссия җирендә Двина елгасын кичеп, плацдарм яулый һәм саклап кала. Июль аенда Советлар Союзы Герое исеменә күрсәтелә. Шул ук ай ахырында орден белән бүләкләнә. 1945 елның 24 мартында Латвия җирендә яраларыннан вафат була.

Тагын бер Герой – Габбас Рәхмәтуллин. Аның турында Кайбыч районы Герое дип төрле чыганакларда язып чыктылар. Кызыксынгач, билгеле булды. Герой артиллерист, кече лейтенант Габбас Рәхмәтуллин бүгенге Апас районы Сатламыш авылында туган. Армиягә, әлбәттә, Кайбычтан киткән һәм 1946 елда Кайбычка кайткан. Шуңа күрә, беркайда да, Кайбычтан кала, бүтән район исеме яңгырамый. Әле 1939 елда Халхин-Гол сугышында катнаша. 1945 елның 22 февралендә Польша шәһәрендә Одер елгасын кичкәндә аеруча зур батырлыкларга ирешә. Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә. Сугыш беткәч, май ахырында Ленин ордены тапшырыла.

Күрәбез, Кайбыч районында рәсми рәвештә Герой исемен алучылар да шактый. Төрле дивизия, бригада, армия командирлары тарафыннан зур батырлыклар күрсәткән өчен Советлар Союзы Герое исеменә лаек дип тәкъдим ителгән, ләкин төрле сәбәпләр аркасында бу югары исем урынына бүләк орденга алыштырылган очраклар тагын да күбрәк булып чыкты. Без монда алты герой, Әбрар Җәләлиевны исәпләсәк, җиде геройны искә алдык. Тора-бара, бәлкем, тагын да ачыкланырлар әле. Бу мәгълүматларны табып биргән өчен республикабызның атаклы эзтабары Михаил Черепановка һәм якташыбыз, безгә бик күп мәгълүмат җиткерүче Рәхимулла абый Гарифуллинга олы рәхмәтләребезне җиткерәбез. Батырлар даны мәңгелек!

**Рәмис Хәялиев,
Олы Кайбыч**